Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге Советы

КАРАР

№ 16 18. 01. 2016 ел

**Сөнчәле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, 2004 елның 24 мартындагы 18 статьясына ярашлы № 23-ЗРТ «җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Сөнчәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы белән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Сөнчәле авыл җирлеге Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2016 елның 6 мартында якшәмбе көнне 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2016 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә урнашкан, шулай ук теркәлмәгән, әмма җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, Сөнчәле авыл җирлеге территориясендә яшәүче яки милекләре булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын еллык бер тапкыр түләүне кертүгә ризамы, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп:

Дорожная деятельность в отношении автомобильных дорог местного значения в границах населенных пунктов поселения.- щебеночное покрытие, обсыпка грунтом, выравнивание в с.Сунчелеево – по улицам: К.Маркса, Маяковского, Молодёжная, Ленина – 180000,00 ( сто восемьдесят тысяч) рублей

2.Торак пункт чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру

- ВНБ, тирәнлек насосы сатып алу, Кече Сөнчәле авылында ВНБ урнаштыру - 50000,00 (илле мең) сум

ӘЙЕ ЮК

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум округын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм

Сөнчәле авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.

5. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге участок сайлау комиссиясе гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Сөнчәле авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

6. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында да.

Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге
Совет Рәисе: И.В.Крайнова

СОВЕТ СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ